Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLIII-11**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге ХХ-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә үзидарәлек җир контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль законга, 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм үзидарәлек контролен гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2019 елның 25 мартындагы 02-06-2019/28 номерлы протестын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге ХХ-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирдән файдалануга үзидарәлек җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 27.1 пункты белән тулыландырырга:

"Планлы тикшерү уздырганда үзидарәлек җир контроле органы тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлеге) кулланырга бурычлы. Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлеген) файдалану барлык юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшергәндә гамәлгә ашырыла. Планлы тикшерү уздырганда кулланылучы тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлеге) юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга куела торган мәҗбүри таләпләргә кагылучы, аларны үтәү гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә зыян китерү куркынычы барлыкка килүне, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш вазгыятьләрне булдырмау күзлегеннән караганда аеруча мөһим булып торган сорауларны үз эчләренә алалар. Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны планлы тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә (контроль сораулар исемлегенә) кертелгән сораулар исемлеге белән чикләнә";

Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 3.5.1 бүлеге белән тулыландырырга:

“3.5.1.Тикшерүләр реестрын алып бару.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген), үзидарәлек контролен гамәлгә ашырганда уздырыла торган тикшерүләрнең, шулай ук аларның нәтиҗәләренең исәбен тәэмин итү максатларында тикшерүләрнең бердәм реестры булдырыла. Тикшерүләрнең бердәм реестры федераль дәүләт мәгълүмат системасы булып тора. Тикшерүләрнең бердәм реестрының операторы – Россия Федерациясе Генераль прокуратурасы.

Тикшерүләрнең бердәм реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана. Күрсәтелгән кагыйдәләр белән тәгаенләнә:

1) тикшерүләрнең бердәм реестрын төзү һәм кулланылышка кертү тәртибенә таләпләр;

2) автоматик режимда тикшерүнең исәп номерын бирү тәртибе;

3) тикшерү, аның нәтиҗәләре һәм ачыкланган бозуларның нәтиҗәләрен туктату һәм (яки) бетерү буенча күрелгән чаралар турында тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән мәгълүмат составы, бу реестрга әлеге мәгълүматны кертү сроклары һәм тәртибе;

4) тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына бирелергә тиешле мәгълүмат составы, аны бирү тәртибе;

5) тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиешле дәүләт контролен (күзәтчелеген), үзидарәлек контролен гамәлгә ашыру турында бүтән мәгълүмат составы.

Тикшерүләрнең бердәм реестры операторы тикшерүләрнең бердәм реестрыннан түбәндәге һәркем өчен керү мөмкинлегенә ия мәгълүматны “Интернет” челтәренең махсуслашкан сайтында урнаштыруны тәэмин итә:

1)тикшерүнең исәп номеры;

2)үзидарәлек контроле органы карамагында билгеләнгән (күрсәтелгән) һәм 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм үзидарәлек контролен гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 294-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе 2 өлешенең 1 – 6 һәм 9 пунктларында күздә тотылган мәгълүмат;

3) тикшерү актында күрсәтелгән һәм 2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм үзидарәлек контролен гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 294-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 2 өлешенең 1 – 6 пунктларында күздә тотылган мәгълүмат;

4) тикшерү нәтиҗәләрен күрсәтү (тикшерү барышында мәҗбүри таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда расланган таләпләрнең бозылуы беленгәнме);

5) тикшерү уздырганда беленгән бозуларга карата күрелгән чараларны, ачыкланган бозуларны бетерү турында һәм (яки) китерелгән зыянны булдырмау буенча чаралар үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга күрсәтмә бирүне, административ хокук бозу турындагы эш буенча производствоны тәэмин итү чараларын куллануны, гаепле затларны административ җаваплылыкка

тартуны, элек бирелгән рөхсәт итүләрне, лицензияләрне, аккредитация аттестатларын һәм рөхсәт итү характерындагы бүтән документларны туктату яки гамәлдән чыгару, продукцияне кире кайтару (чакыртып алу), мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль хокукый актлар белән расланган таләпләрне беленгән бозулар турында материалларны компетенцияләренә ярашлы рәвештә дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрүне дә кертеп, муниципаль контроль органының , аларның вазыйфаи затларының тиңдәшле карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр һәм ул шикаятьләрнең нәтиҗәләре турында күрсәтү.

Тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару, аңа тиешле мәгълүматны кертү һәм аны ачу Россия Федерациясенең дәүләт һәм закон белән саклanучы бүтән сере турында законнар таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылалар.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Вафин Ф.М.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов